**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**бишенче чакырылыш чираттан тыш утырыш**

**Үзәк п.** **30 март 2026 ел**

**№ 32**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл жирлегенең 28.10.2014г. № 186 номерлы «Ваклап сату челтәренең эш тәртибен һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урам сәүдәсен оештыру тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Әйләнә-тирә тәмәке төтене йогынтысыннан, тәмәке тарту яисә никотинлы продукция куллану нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында» Федераль законның 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 551-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге советы карар итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Советынын 28.10.2014 ел № 186 «Ваклап сату челтәренең эш тәртибен һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урам сәүдәсен оештыру тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге территориясендә ваклап сату сәүдә челтәренең эш кагыйдәләренә һәм урам сәүдәсен оештыру тәртибенә:

1) 1.4 пунктның 1 пунктчасында «шәһәр яны маршрутларына),» сүзләрен «шәһәр яны маршрутларына) һәм аның хәрәкәтенең тукталыш пунктларында (мондый тукталыш пунктында урнаштырылган сәүдә объекты тәмәке продукциясен яисә никотинлы продукцияне, кальяннар, никотинлы продукциясен куллану җайланмаларын сатуның бердәнбер урыны булган очрактан тыш) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Үзәк авыл җирлеге башлыгы В.Н. Котников